РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ
ТЕТЮШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
422370 г.Тетюши, ул. Малкина, 39

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТӘТЕШ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
422370 Тәтеш шәһәре, Малкин ур., 39

тел. (84373) 2-50-02, 2-53-33, факс 2-62-48, e-mail: tatesh@tatar.ru
ОКПО 78702080, ОГРН 1061672000026, ИНН/КПП 1638004985/163801001

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
16.03.2020

**КАРАР**
№ 142

**«2020 елга Тәтеш муниципаль районы халкына бирелә торган торак-коммуналь хезмәтләр өчен түләү күләмен раслау турында»гы Тәтеш муниципаль районы башкарма комитетының 2020 елның 16 гыйнварындагы 28 номерлы карарының 1 нче кушымтасына үзгәрешләр кертү турында**

«Коммуналь комплекс оешмалары тарифларын көйләү үзлекләре турында»гы 2004 елның 30 декабрендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «2020 елга Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә коммуналь хезмәтләр күрсәтүгә гражданнар тарафыннан кертелә торган түләү күләмен үзгәртүнең чик индекслары турында»гы 2019 елның 14 декабрендәге УП-746 номерлы Татарстан Республикасы Президенты Указы, «Татарстан Республикасындагы күп фатирлы йортлардагы гомуми милекне капиталь ремонтлау өчен взносның минималь күләме турында»гы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 29 июнендәге 450 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында»гы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 3 декабрендәге 1097 номерлы карары нигезендә, Тәтеш муниципаль районы башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. «2020 елга Тәтеш муниципаль районы халкына бирелә торган торак-коммуналь хезмәтләр өчен түләү күләмен раслау турында»гы Тәтеш муниципаль районы башкарма комитетының 2020 елның 16 гыйнварындагы 28 номерлы

карарының 1 нче кушымтасына үзгәрешләр кертергә.

1.1 1 нче кушымтага түбәндәге эчтәлекле 9 нчы юлны өстәргә:

| Түләү исемлеге | Түләү алынган үлчәү берәмлеге | 01.01.2020 елдан 30.06.2020 елга кадәр хезмәтне үлчәү берәмлеге тарифы | 01.07.2020 елдан 31.12.2020 елга кадәр хезмәтне үлчәү берәмлеге тарифы |
|---|---|---|---|
| | | (сумнарда) | (сумнарда) |
| “Тәтеш Жилсервис” ҖЧҖ ИК күпфатирлы йортларда вентиляция каналларын һәм төтен юлларын ремонтлау | аена торак бинаның гомуми мәйданы кв. м | 0,77 | 0,80 |
| | | | |

2. Әлеге карарны Тәтеш муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга һәм «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

3. Әлеге карарны гамәлгә ашыруны контрольдә тотуны үз өстемә алам.

**Тәтеш муниципаль районы**
**башкарма комитеты**
**җитәкчесе** **А.Б. Семенычев**